**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«16» сентябрь 2022 ел　　　Иске Дөреш авылы　　　№10

Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 8 апрелендәге 6 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2022 елның 1 июлендәге 02-06-2022/9 номерлы протесты, Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 8 апрелендәге 6 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　Р.М. Дусадбеков